**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актанышав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ 21.06.2024 № ПР-114 КАРАР № _____

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2024 елга муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында» 2024 елның 23 маендагы ПР-88 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы- «Зөбәер балалар бакчасы» эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору датасына үзгәрешләр кертү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2024 елның җәйге чорына муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында» 2024 елның 23 маендагы ПР-88 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта вакытлыча туктатылган мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре исемлегеннән «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе-«Зөбәер балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен төшереп калдырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы-«Зөбәер балалар бакчасы» эшчәнлеген 2024 елның 1 июненнән 1 июленә кадәр туктатырга.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Җитәкче Р.А.Ильясов